**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 25.02.2020** **№ 229**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча укуга кабул итүне оештыру турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турындагы» 2012 нче елның 29 нчы декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 1 өлешен гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 нче елның 22 нче январендәге 32 нче номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Түбәндә китерелгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча гражданнарны белем алуга кабул итү Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең интернет челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып халыкка җиткерергә.

3. Карар үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары –мәгариф бүлеге начальнигы Н.К. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

«Расланды»
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 нче елның 25 нче февралендәге
229 нчы номерлы
Карары белән

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча укуга кабул итү**
**ТӘРТИБЕ**

1. Гражданнарны башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү тәртибе (алга таба - Тәртип) Россия Федерациясе гражданнарын (алга таба - гражданнар, балалар) башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда кабул итүне регламентлаштыра (алга таба -ОООД, гомуми белем бирү программалары).

2. Гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү кагыйдәләре (алга таба - кабул итү кагыйдәләре) мәгариф турындагы законнар белән җайга салынмаган өлештә, ОООД тарафыннан мөстәкыйль рәвештә билгеләнә. ОООД филиалында белем алу өчен гражданнарны кабул итү ОООДда укырга кабул итү кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Муниципаль мәгариф оешмаларына төп гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү кагыйдәләре тиешле дәрәҗәдәге гомуми белем алуга хокукы булган һәм күрсәтелгән белем бирү оешмасы беркетелгән территориядә яшәүче гражданнарны белем бирү оешмасына кабул итүне тәэмин итәргә тиеш (алга таба - беркетелгән территория).

4. Россия Федерациясендә мәгариф турындагы" 2012 нче елның 29 нчы декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 67 нче статьясының 5 һәм 6 нчы өлешләрендә һәм 88 нче статьясында каралган очраклардан тыш, муниципаль мәгариф оешмасына кабул итү анда буш урыннар булмау сәбәпле генә кире кагылырга мөмкин. (Россия Федерациясе законнары Җыентыгы, 2012, N 53, 7598 ст.; 2013, N 19, 2326 ст.; N 23, 2878 ст.; N 27, 3462 ст.; N 30, 4036 ст.; N 48, 6165 ст.). Муниципаль белем бирү оешмасында урыннар булмаган очракта, баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) аны башка гомуми белем бирү оешмасына урнаштыру мәсьәләсен хәл итү өчен турыдан-туры мәгариф өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органына мөрәҗәгать итә.

5. Федераль бюджетның, Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының һәм җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре акчалары исәбеннән төп гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү һәркем файдалана алырлык нигездә үткәрелә, әгәр дә "Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 нче елның 29 нчы декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда (Россия Федерациясе

законнары җыентыгы) башкасы каралмаган булса.

6. Аерым уку предметларын тирәнтен өйрәнү белән яисә профильле укыту өчен төп гомуми һәм урта гомуми белем алу өчен муниципаль мәгариф оешмаларына кабул ителгәндә, индивидуаль сайлап алуны оештыру Россия Федерациясе субъекты законнарында каралган очракларда һәм тәртиптә рөхсәт ителә.

Физик культура һәм спорт өлкәсендә өстәмә һөнәри белем бирү программалары белән интеграцияләнгән төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына гражданнарны кабул иткәндә конкурс яисә индивидуаль сайлап алу оештыру яисә сәнгать өлкәсендә урта һөнәри белем бирү буенча төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары белән интеграцияләнгән уку-укыту программалары сәнгатьнең яисә спортның аерым төре белән шөгыльләнүгә сәләтләрне бәяләү нигезендә, шулай ук тиешле спорт төре белән шөгыльләнүгә каршылыклар булмаганда гамәлгә ашырыла.

7. ОООД укырга керүчене һәм (яки) аның ата-анасын (законлы вәкилләрен) үз уставы, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе, дәүләт аккредитациясе турында таныклык, белем бирү программалары һәм белем бирү эшчәнлеген оештыруны һәм гамәлгә ашыруны регламентлаштыручы башка документлар белән, укучыларның хокуклары һәм бурычлары белән таныштырырга бурычлы.

Муниципаль мәгариф оешмалары муниципаль районның җирле үзидарә органының мәгариф оешмаларын муниципаль районның конкрет территорияләренә беркетү турында боерык актын агымдагы елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча урнаштыралар (алга таба - беркетелгән территория турында боерык акты).

8. Балигъ булмаган укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) бала фикерен исәпкә алып, шулай ук психолог-медик-педагогик комиссия (булган очракта) тәкъдимнәрен исәпкә алып, төп гомуми белем алуны тәмамлаганчы, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешма тәкъдим итә торган исемлектән белем алу формасын һәм белем бирү формасын, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманы, тел, белем алу телләрен, факультатив һәм электив уку предметларын, курсларны, дисциплиналарны (модульләр) сайлау хокукына ия.

9. Гражданнарны беренче сыйныфка оешкан төстә кабул итү максатында муниципаль белем бирү оешмасы мәгълүмати стендта, "Интернет" челтәрендәге рәсми сайтта, массакүләм мәгълүмат чараларында (шул исәптән электрон) түбәндәге мәгълүматны урнаштыра:

беркетелгән территория турында боерык акты басылып чыкканнан соң, 10 календарь көннән дә соңга калмыйча беренче сыйныфларда урыннар саны турында;

1 июльдән дә соңга калмыйча беркетелгән территориядә яшәмәгән балаларны кабул итү өчен буш урыннар булу турында.

10. ОООДга гражданнарны кабул итү баланың ата-анасының (законлы вәкиленең) шәхси гаризасы буенча, ата-ананың (законлы вәкилнең) затның шәхесен таныклый торган документның төп нөсхәсен күрсәтеп, яки "Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турындагы" 2002 нче елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы нигезендә Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документның төп нөсхәсен күрсәтеп гамәлгә ашырыла. (Россия Федерациясе законнары Җыентыгы, 2002, N 30, 3032 ст.).

ОООД күрсәтелгән гаризаны кабул итүне гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып электрон документ рәвешендә гамәлгә ашырырга мөмкин.
Баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) тарафыннан гаризада түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:
а) баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);
б) баланың туган көне һәм туган урыны;
в) баланың ата-анасының (законлы вәкилләренең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта); ;
г) баланың, ата-анасының (законлы вәкилләренең) тору урыны адресы;
д) баланың ата-анасының (законлы вәкилләренең) элемтә телефоннары.
Гаризаның якынча формасы ОООДның мәгълүмат стендында һәм (яисә) ОООДның "Интернет" челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.
ОООДга кабул итү өчен:
беркетелгән территориядә яшәүче балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) баланы беренче сыйныфка алу өчен өстәмә рәвештә баланың туу турында таныклыгының төп нөсхәсен яисә мөрәҗәгать итүченең туганлыгын раслый торган документ, баланы яшәү урыны яисә беркетелгән территориядә тору урыны буенча теркәү турында таныклык яисә беркетелгән территориядә яшәү урыны буенча яисә булу урыны буенча белешмәләр булган документ күрсәтәләр;
бер гаиләдә яшәүче һәм гомуми яшәү урыны булган балалар мәктәпкәчә белем бирүнең һәм башлангыч гомуми белем бирүнең төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алу өчен абыйлары һәм (яисә) апалары укый торган муниципаль мәгариф оешмаларына укырга керүгә өстенлекле кабул итү хокукына ия;
беркетелгән территориядә яшәмәгән балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) өстәмә рәвештә баланың туу турында таныклыгын күрсәтәләр.
Чит ил гражданнары яисә гражданлыгы булмаган затлар булган балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) өстәмә рәвештә гариза бирүченең туганлыгын (яисә бала хокукларын тәкъдим итүнең законлылыгын) раслый торган документ һәм мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясендә булу хокукын раслый торган документ күрсәтәләр.
Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар барлык документларны рус телендә яисә билгеләнгән тәртиптә расланган рус теленә тәрҗемә белән бергә бирәләр.

Документлар кабул иткәндә тапшырыла торган документларның күчермәләре баланың укыган вакытында ОООДда саклана.

11. Балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) үзләре теләгәнчә башка документлар тапшырырга хокуклы.

11.1. Башлангыч гомуми һәм төп гомуми белем бирүнең дәүләт аккредитациясе булган белем бирү программалары буенча укырга кабул ителгәндә, Россия Федерациясе халыклары телләре арасыннан туган телне, шул исәптән туган тел буларак рус телен, Россия Федерациясе республикаларының дәүләт телләрен сайлап алу балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) гаризасы буенча гамәлгә ашырыла.

12. ОООДда урта гомуми белем алу өчен кабул ителгәндә билгеләнгән үрнәктәге төп гомуми белем турындагы аттестат тапшырыла.

13. ОООДга балаларны кабул итү өчен нигез буларак башка документлар бирүне таләп итү рөхсәт ителми.

14. Баланың ата-аналарын (законлы вәкилләрен) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия, ОООД дәүләт аккредитациясе турында таныклык, ОООД уставы, белем бирү программалары һәм белем бирү эшчәнлеген оештыруны һәм гамәлгә ашыруны регламентлаштыручы документлар белән, укучыларның хокуклары һәм бурычлары белән таныштыру факты кабул итү турындагы гаризада теркәлә һәм баланың ата-анасының (законлы вәкилләренең) шәхси имзасы белән таныклана.

Баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) имзасы белән шулай ук аларның шәхси белешмәләрен һәм баланың шәхси мәгълүматларын Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә эшкәртүгә ризалыгы теркәлә.

15. Беркетелгән территориядә яшәүче гражданнар өчен ОООД ның беренче сыйныфына гаризалар кабул итү 1 февральдән дә соңга калмыйча башлана һәм агымдагы елның 30 июненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

ОООДга кабул итү документлар кабул ителгәннән соң 7 эш көне дәвамында ОООД боерык акты белән рәсмиләштерелә. Беркетелгән территориядә яшәмәгән балалар өчен беренче сыйныфка гаризалар кабул итү агымдагы елның 1 нче июленнән башлап буш урыннарны тутырганчы, агымдагы елның 5 нче сентябреннән дә соңга калмыйча башлана.

Беркетелгән территориядә яшәүче барлык балаларны беренче сыйныфка кабул итүне тәмамлаган ОООД беркетелгән территориядә яшәмәүче балаларны 1 июльдән иртәрәк кабул итә.

16. ОООД балаларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) уңайлы булсын өчен, яшәү урыны (тору) буенча теркәлү адресына бәйле рәвештә документларны кабул итү графигын билгелиләр.

17. Беркетелгән территориядә яшәмәгән балаларны буш урыннарга кабул иткәндә, Россия Федерациясе законнары һәм Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары нигезендә ОООДга беренче чиратта урын бирелү хокукына ия булган гражданнарның балалары өстенлекле хокукка ия.

18. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар адаптацияләнгән төп гомуми белем бирү программасы буенча укуга аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) ризалыгы белән һәм психология-медицина-педагогика комиссиясе тәкъдимнәре нигезендә генә кабул ителә.

19. Балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) тапшырган документлар гаризалар кабул итү журналында теркәлә. Балаларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) гариза теркәлгәннән соң документларны кабул итү турында баланы ОООДга кабул итү турында гаризаның теркәү номеры, тапшырылган документлар исемлеге турында мәгълүматны үз эченә алган расписка бирелә. Расписка документлар кабул итү өчен җаваплы ОООД вазыйфаи затының имзасы һәм ОООД мөһере белән таныклана.

20. Балаларны укырга кабул итү турындагы ОООДның боерык актлары аларны бастыру көнендә ОООДның мәгълүмат стендында урнаштырыла.

21. ОООДга кабул ителгән һәр балага аның барлык тапшырылган документлары саклана торган шәхси эш ачыл